ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2021 елның 16 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге территориясендә Шахмай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, моннан тыш, көндезге уку формасында укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче 1 төркем инвалидларыннан тыш, 1000 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны Шахмай авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (материал сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), Чишмә, Яңа, Х. Хәйруллин, Үзәк урамнар буенча;
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, МТЗ-320 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу);
- зиратны төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, капка урнаштыру, коры агачларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылы мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// novosheshminsk. tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка танытырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов